РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма, ул.Ленина, д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

13.11.2024 — № 25

Саба муниципаль районыИске Икшермә авыл җирлеге Советының 28.04.2018 №10 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.09.2024 елгы №829 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә»нең 28.04.2018 елгы №10 карарына (Советның 09.11.2020 №10, 20.10.2022 №22, 19.12.2022 №28 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13 990 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарның 1 нче кушымтасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл

җирлеге үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керәчәк яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча урнаштырырга.

Иске Икшермә авыл
җирлеге башлыгы: А.И.Биккинин

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
Районы Иске Икшермә авыл җирлеге
Советының 13.11.2024 №25 карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге Башлыгы | 19 173 |
| Депутатлар | 13 990 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13 990 |